РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«2» март 2022г.

с. Тюлячи

№ 29

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 10 декабрендәге 530 номерлы «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Финанс-бюджет палатасының 2022 елның 17 февралендәге 01-14/15 номерлы хатын карап, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 октябрендәге 1029 номерлы карары нигезендә, район халкының тормыш сыйфатын яхшырту максатларында һәм Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф ставкаларын (окладларын) күтәрү зарурлыгына бәйле рәвештә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 10 декабрендәге 530 номерлы «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында» карарына (2018 елның 31 гыйнварындагы 61 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 елның 18 августындагы 592 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләренең хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелмәгән хезмәткәрләре өчен 2018 елның 1 гыйнварыннан билгеләргә:

Теләче муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)1 номерлы  кушымта нигезендә.».

- 1.1-1.2 пунктлар үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы – территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«_2_» _03_ 2022 № _29_
карарына 1 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)**

| Бердәм тариф челтәре өчен түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тарифлы ставкалар (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 13 617,0 |
| 2 | 1,0178 | 13 860,0 |
| 3 | 1,0362 | 14 110,0 |
| 4 | 1,0538 | 14 350,0 |
| 5 | 1,0736 | 14 620,0 |
| 6 | 1,0927 | 14 880,0 |
| 7 | 1,1133 | 15 160,0 |
| 8 | 1,1331 | 15 430,0 |
| 9 | 1,1530 | 15 700,0 |
| 10 | 1,1743 | 15 990,0 |
| 11 | 1,1948 | 16 270,0 |
| 12 | 1,2168 | 16 570,0 |
| 13 | 1,2389 | 16 870,0 |
| 14 | 1,2609 | 17 170,0 |
| 15 | 1,2837 | 17 480,0 |
| 16 | 1,3072 | 17 800,0 |
| 17 | 1,3307 | 18 120,0 |
| 18 | 1,3549 | 18 450,0 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладлары) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.